# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану турында

Әлеге Закон Татарстан Республикасы территориясендә мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалануның хокукый, икътисадый һәм оештыру нигезләрен һәм тәртибен билгели.

Әлеге Законның максаты мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә, аларны бүгенге һәм киләчәк буыннар өчен саклап калу өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салудан гыйбарәт.

### I. Гомуми нигезләмәләр

**<u>1 статья.</u>** Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану турындагы законнар

Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану турындагы законнар әлеге Законнан һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган башка закон актларыннан гыйбарәт.

Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне исәпкә алуның, саклауның һәм алардан файдалануның әлеге Закон тарафыннан билгеләнгән тәртибе, милек рәвешләренә карамастан, барлык мәдәни һәм тарихи хәзинәләргә карата да кулланыла.

**<u>2 статья.</u>** Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану өлкәсендәге законнарның бурычлары

Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану өлкәсендәге законнарның бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- мәдәни һәм тарихи хәзинәләрнең статусын билгеләү;
- мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану эшендә дәүләт идарәсе һәм хакимияте органнарының, хокукый һәм физик затларның хокукларын һәм бурычларын билгеләү;
- мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклауга юнәлгән гамәлләрне тәэмин итү.

3 статья. Төп төшенчәләр

Мәдәни һәм тарихи хәзинәләр - җәмгыять өчен һәм Татарстан Республикасы күпмилләтле халкының мәдәни һәм табигый тереклек мохитенең үзенчәлеген һәм күптөрлелеген саклап калу өчен әһәмияте булган билгеле бер мәдәният белән, истәлекле бер факт яисә тарихи бер вакыйга белән бәйле һәйкәлләр, территорияләр һәм объектлар, әхлакый һәм эстетик идеаллар, телләр, милли традицияләр һәм гореф-гадәтләр, халык авыз иҗаты, кәсепләр һәм һөнәрләр ул.

Мәдәни һәм тарихи мирас - кеше һәм табигать тудырган мәдәни һәм тарихи хәзинәләр җыелмасы, шулай ук халыкның, җәмгыятьнең яисә күренекле шәхесләрнең рухи дөньясының тарихи, фәнни-техник, сәнгати, табигый-экологик, этнологик яисә башка төр мәдәни әһәмияткә ия күренешләре ул.

Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау - мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне барлау-табу, исәпкә алу, саклап калу, реставрацияләү һәм алардан нәтиҗәле файдалану өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга салучы хокукый, оештыру, финанс гамәлләре һәм башка төрле гамәлләр системасы ул.

Күчерелми торган мәдәни һәм тарихи хәзинәләрнең территорияләре - әлеге хәзинәләр биләүче һәм алар белән композиция һәм тарихи яктан бәйле кишәрлекләр ул, аларга карата кулланунын махсус шартлары билгеләнә.

Күчерелми торган мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау зоналары - әлеге хәзинәләрнең территорияләреннән читтә урнашкан мәйданнар ул, аларга карата куллануның махсус шартлары билгеләнә.

Тарихи һәм мәдәни ядкярләрне саклау буенча дәүләт органнары - мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә идарә һәм тикшереп тору вазыйфаларын башкаручы

дәүләт идарәсе органнары ул.

Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау буенча дәүләт оешмалары - дәүләт музейлары, китапханәләре, архивлары, музей-тыюлыклары, табигать кочагында урнашкан музейлар һәм хәзинәләрне дәүләт тарафыннан саклауны гамәлгә ашыручы башка оешмалар ул.

Реставрацияләү - мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне булдыра алган кадәр башлангыч асылында саклап калу йөзеннән уздырылучы тикшеренү, проектлаштыру һәм җитештерү эшләре җыелмасы ул.

4 статья. Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрнең хокукый хәле

Татарстан Республикасы территориясендәге мәдәни һәм тарихи хәзинәләр - Татарстан Республикасы күпмилләтле халкының байлыгы ул.

Мәдәни һәм тарихи хәзинәләр бөтен кеше өчен ачык һәм алар фәнне, мәгарифне, мәдәниятне һәм туризмны үстерү максатларында файдаланылалар. Әгәр мондый файдалану мәдәни һәм тарихи хәзинәләрнең сакланышына зыян китермәсә һәм аларның тарихи-сәнгати кыйммәтен бозмаса, алардан хуҗалык итү максатларында файдалану рөхсәт ителә.

Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрдән файдалану әлеге Закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

Мәдәни һәм тарихи хәзинәләр, законнарда каралган очраклардан гайре, хосусыйлаштырылмый.

5 статья. Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрнең төрләре

Әлеге Закон максатларында мәдәни һәм тарихи хәзинәләр түбәндәге төрләргә бүленәләр:

Күчерелми торган мәдәни һәм тарихи хәзинәләр:

- тарих ядкярләре - халык, җәмгыять һәм дәүләт тормышындагы мөһим вакыйгалар белән, фән һәм техника, халыкларның мәдәнияте һәм көнкүреше үсеше белән, күренекле сәяси, дәүләти, иҗтимагый, хәрби эшлеклеләр, халык каһарманнары, фән, әдәбият һәм сәнгать әһелләре тормышы белән бәйле бинапар, корылмалар һәм урыннар ул;

- археология ядкярләре - шәһәрчекләр, валлар һәм башка ныгытмалар, курганнар, борынгы торак урыннарының, борынгы ны-

гытмаларның, борынгы җитештерү урыннарының, каналларның, юлларның калдыклары, борынгы каберлек урыннары, таш сыннар, эпиграфик объектлар, кыялардагы сурәтләр, хәзинәләр һәм комплекслар, гыйбадәт кылу урыннары, иң борынгы торак пунктларының тарихи һәм мәдәни катламы урнашкан кишәрлекләр ул;

- архитектура һәм шәһәр төзелеше ядкярләре - тарихи үзәкләр, кремльләр, кварталлар, мәйданнар, урамнар, яр буйлары, борынгы торак пунктларын планлаштыру һәм төзү калдыклары; гражданнар, сәнәгать, хәрби һәм дини архитектура корылмалары, халык осталары төзегән корылмалар, шулай ук алар белән бәйле монументаль, сынлы сәнгать, декоратив-гамәли, бакча-парк сәнгате әсәрләре, тарихи һәм табигый ландшафтлар ул;

- сәнгать ядкярләре - скульптура һәйкәлләре, стелалар, обелисклар ул;

- тарих-архитектура ансамбльләре һәм комплекслары - тарих, сәнгать һәм фән күзлегеннән чыгып караганда, үзләренең архитектура бөтенлекләре ягыннан, тарих һәм ландшафт белән бәйле булулары ягыннан аеруча зур әһәмияткә ия булган аерым-аерым урнашкан яисә берләштерелгән корылмалар төркемнәре ул;

- тарихи-мәдәни әһәмияткә ия җирләр - тарихи-мәдәни тыюлыклар, мемориаль парклар, каберлекләр, археология, тарих һәм архитектура ядкярләре, архитектура-ландшафт комплекслары биләүче җирләр ул;

- тарихи торак пунктлары - Татарстан Республикасындагы тарих-архитектура ягыннан, ландшафты ягыннан һәм башка яктан аеруча зур әһәмияткә ия шәһәрләр һәм бүтән торак пунктлары ул.

Күчерелә торган мәдәни һәм тарихи хәзинәләр:

- архивлар һәм архив документлары - Татарстан Республикасы күпмилләтле халкының тарихы турындагы документлар, дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының, дини, иҗади һәм башка оешмаларның актлары, шулай ук тарихи әһәмияткә ия шәхси документлар ул;

- кино- һәм фотодокументлар - кинофильмнарның, видеоязмаларның негативлары, кинoплакатлар, фән өчен, кино сәнгате һәм мәдәният өчен әһәмияте булган фотографияләр һәм башка төрле видеодокументлар ул;

- борынгы һәм сирәк очрый торган китаплар, уникаль архео-

логик һәм библиографик хәзинәләр - күренекле шәхесләргә бәйле яисә башка төрле әһәмияткә ия кулъязмалар, кулдан язылган һәм басма китаплар, көндәлек матбугат басмалары, китапханә коллекцияләре һәм тупланмалары, музыка, әдәбият һәм театр сәнгате әсәрләре ул;

- сәнгать хәзинәләре - сынлы сәнгать, монументаль һәм декоратив-гамәли сәнгать әсәрләре, хакыйкый интерьерлар һәм аларның җыһазлары, сынлы сәнгать, дизайн, архитектура өлкәсендәге проектлар, театр декорацияләре һәм костюмнары, халык кием-салымнары, йорт кирәк-яраклары үрнәкләре һәм сәнгать әсәрләре булып саналырлык башка предметлар, музейларның тарихи яктан оешкан коллекцияләре, сәнгать буенча шәхси коллекцияләр, һөнәрчеләр җитештергән кайбер әйберләр ул;

- фәнни-тарихи реликвияләр - археология, нумизматика, табигать турындагы фәннәр, филателия, геральдика һәм этнография өлкәсеннән тарихи вакыйгалар һәм шәхесләр белән бәйле әйберләр, предметлар, табылдыклар, фән һәм техниканың уникаль үрнәкләре, борынгы мебель, гобеленнар, келәмнәр, костюмнар, кием-салым, музыка кораллары, гыйбадәт кылу әйберләре, корал һәм җәмгыять өчен тарихи һәм мәдәни әһәмияте булган башка нәрсәләр ул;

- халык авыз иҗаты - телдән тапшырылучы җырлар, поэзия, проза, драматургия әсәрләре, шулай ук халык музыка, хореография әсәрләре һәм гореф-гадәт гамәлләре ул.

<u>6 статья.</u> Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне классификацияләү

Мәдәни һәм тарихи хәзинәләр мөһимлекләре ягыннан җирле, республика, федераль һәм халыкара мәдәни һәм тарихи хәзинәләргә бүленәләр.

Җирле әһәмияткә ия мәдәни һәм тарихи хәзинәләргә әлеге төбәккә хас объектлар кертеләләр.

Республика әһәмиятенә ия мәдәни һәм тарихи хәзинәләргә Татарстан Республикасы күпмилләтле халкының матди һәм рухи мәдәниятен танып белү өчен тарихи, фәнни, сәнгати әһәмияте булган объектлар кертеләләр.

Тарихи, археологик, мәдәни, фәнни һәм сәнгати яктан үрнәк булырлык мәдәни һәм тарихи хәзинәләр, фән һәм мәдәният оешма-

лары һәм учреждениеләре Татарстан Республикасы Мәдәни мирасының аеруча әһәмиятле объектлары җыелмасына кертеләләр.

Объектларны федераль әһәмияткә ия мәдәни һәм тарихи хәзинәләргә кертү тәртибе Россия Федерациясе законнары тарафыннан билгеләнә.

Аеруча кыйммәтле мәдәни һәм тарихи хәзинәләр һәйкәлләрне һәм тарихи урыннарны саклау буенча халыкара совет (ИКОМОС) һәм ЮНЕСКОның Бөтендөнья мәдәни һәм тарихи мирасы комитеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Бөтендөнья мәдәни мирасы исемлегенә кертеләләр һәм махсус сак астында булалар.

## II бүлек. Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә идарә

### 7 статья. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану өлкәсендәге вәкаләтләре

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карамагына түбәндәгеләр керә:

- мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану өлкәсен законнар белән җайга салу;
- мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану буенча дәүләт сәясәтен билгеләү, дәүләт программаларын раслау;
- Татарстан Республикасы республика бюджетының мәдәни һәм тарихи ядкярләрне саклауга һәм реставрацияләүгә тотылучы чыгымнары өлешен, законнар нигезендә салым ташламалары билгеләүне раслау;
- дәүләт милкендәге мәдәни һәм тарихи хәзинәләрнең милек рәвешләрен үзгәртү мәсьәләләрен хәл итү;
- мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм файдалану өлкәсендәге законнарның үтәлешен тикшереп тору.

### 8 статья. Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә дәүләт идарәсе

Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдала-

ну өлкәсендә дәүләт идарәсе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, тарих һәм мәдәният ядкярләрен саклау буенча дәүләт органнары, шул исәптән дәүләт идарәсенең җирле органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

- мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану буенча хокукый-норматив актлар кабул итү;

- мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә дәүләт сәясәтен башкару, дәүләт программаларын гамәлгә ашыру;

- мәдәни һәм тарихи хәзинәләрнең Республика саклау реестрын раслау, Федераль саклау реестрына һәм Бөтендөнья мәдәни мирасы исемлегенә кертү өчен объектлар исемлеген тәкъдим итү;

- Республика саклау реестрына кертелгән мәдәни һәм тарихи мирас территорияләренең, объектларының, тарихи-мәдәни әһәмияте булган җирләрнең статусын билгеләү;

- реставрация комплексын үстерү;

- һәйкәлләрне саклау зоналарының проектларын раслау, тарихи торак пунктларының җирләре өчен түләү ставкаларын билгеләү тәртибен урнаштыру;

- Татарстан Республикасы территориясеннән читтә урнашкан мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне дәүләтара һәм хөкүмәтара шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә кайгыртып тору.

<u>9 статья.</u> Тарих һәм мәдәният ядкярләрен саклауның дәүләт органнары һәм аларның вәкаләтләре

Татарстан Республикасы территориясендә тарих һәм мәдәният ядкярләрен саклауның дәүләт органнары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы;

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе;

җирле хакимиятләрнең мәдәният идарәләре (бүлекләре).

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе документаль ядкярләрне саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә дәүләт идарәсен үз вәкаләтләре чикләрендә га-

мәлгә ашыра.

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

- мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне һәм тарихи-мәдәни әһәмияткә ия җирләрне файдалану турында Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына тәкъдимнәр кертү;

- ысулый тәкъдимнәрне әзерләү һәм раслау;

- Татарстан Республикасының мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану буенча дәүләт программаларын гамәлгә ашыру;

- дәүләт милкендәге мәдәният һәм тарих ядкярләре белән законннар нигезендә идарә итү һәм аларга хуҗа булу;

- мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне дәүләт исеменнән сатып алу;

- мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне эзләү-барлау, исәпкә алу һәм Саклау реестрын, Татарстан Республикасы Мәдәни мирасының аеруча әһәмиятле объектлары җыелмасын алып бару эшләрен оештыру;

- тарих һәм мәдәният ядкярләрен, аларның территорияләрен, тарихи-мәдәни тыюлыкларны һәм күчерелми торган ядкярләрне саклау зоналарын карап тоту һәм алардан файдалану режимын билгеләү;

- мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау, реставрацияләү һәм алардан файдалану кагыйдәләренең үтәлешен дәүләт тарафыннан тикшереп тору;

- мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау, реставрацияләү һәм алардан файдалану өлкәсендә эшчәнлек алып бару хокукы бирү турында лицензияләр һәм сертификатлар тапшыру, чит ил фирмаларына һәм белгечләренә лицензияләр бирү дә шуңа керә;

- мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне реставрацияләү вакытында заказ бирүче вазыйфаларын үтәү;

- мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау буенча фәнни-ысулый принциплар әзерләүне тәэмин итүче һәм хәзинәләрне саклау буенча гамәли чараларны тормышка ашыручы фәнни, проектлаштыру һәм җитештерү хезмәтләрен булдыру;

- тарихи-мәдәни максатларга хезмәт итүче җирләрне реконструкцияләү һәм төзекләндерү белән, тарих һәм мәдәният ядкярләрен реставрацияләү белән бәйле эшләрнең барлык төрләре буенча

проект документларын карау һәм раслау;

- археологик эзләнүләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле рөхсәтләрне (ачык листларны) теркәү;

- реставрация эшләренең республика программаларын әзерләү һәм раслау;

- мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә фундаменталь фәнни эзләнүләр уздыру, мәгълүмати һәм тәрбия-агарту эшчәнлеген башкару;

- мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану турындагы законнарның нормаларына туры килмәүче проектларны гамәлгә ашыруны туктатып тору;

- мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану буенча халыкара һәм чит ил оешмаларының эшчәнлегендә катнашу;

- мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә дәүләт экспертизасы үткәрү;

- тарихи шәһәрләрнең, башка торак пунктларының, тарих һәм мәдәният ядкярләрен саклау зоналарының генераль планнары проектларын, аларны планлаштыруның, аларда төзелеш эшләре алып баруның һәм аларны реконструкцияләүнең проектларын килештерү;

- законнарда билгеләнгән башка вазыйфаларны башкару.

Янгын куәтүе һәм санитария куәтүе буенча дәүләт органнарының һәм башка органнарның тарих һәм мәдәният ядкярләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендәге таләпләре Татарстан Республикасының тарих һәм мәдәният ядкярләрен саклау буенча дәүләт органнары белән килештерелергә тиеш.

<u>10 статья.</u> Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә дәүләт идарәсенең җирле органнары вәкаләтләре

Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә дәүләт идарәсенең җирле органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

- әлеге Законны үтәүне тикшереп тору;

- мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклауны һәм алардан файдалануны финанслау;

- мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне Республика саклау реест-

рына керту турында тәкъдимнәр биру;

- Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы белән килешеп, мәдәни һәм тарихи хәзинәләрене саклауның җирле реестрын алып бару;

- җирле саклау реестрына кертелгән мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә тикшереп торуны тәэмин итү, аларны теркәү, аларга экспертиза уздыру һәм аларны иминләштерү;

- дәүләт милкендә булган һәм билгеләнгән тәртиптә шушы органнарга тапшырылган мәдәни һәм тарихи хәзинәләр белән идарә итү;

- мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә дәүләт программаларын гамәлгә ашыру.

<u>11 статья.</u> Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне дәүләт тарафыннан исәпкә алу

Күчерелми торган мәдәни һәм тарихи хәзинәләр, милек рәвешләренә карамастан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә дәүләт тарафыннан исәпкә алынырга тиеш. Аларны исәпкә алу Татарстан Республикасы мәдәни мирасының аеруча әһәмиятле объектларының җыелмасын төзү һәм саклау реестрын алып бару рәвешендә эшләнә. Дәүләт исәбен алып бару Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләнә.

Дәүләт исәбен алып бару тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Саклау реестрларына түбәндәгеләр керә:

- яңа гына эзләп табылган күчерелми торган тарихи һәм мәдәни ядкярләр;

- дәүләт саклавында булган күчерелми торган тарих һәм мәдәният ядкярләренең дәүләт исемлеге.

Күчерелми торган тарих һәм мәдәният ядкярләре үзләренә тарихи һәм вазыфаи яктан бәйле территория белән, ул территориядә урнашкан корылмалар һәм күчерелә торган мәдәни һәм тарихи хәзинәләр белән бербөтен буларак дәүләт саклавына алыналар.

Үз фондларында мәдәни һәм тарихи хәзинәләр булган китапханәләр, музейлар һәм архивлар шушы хәзинәләрне билгеләнгән рәвештә исәпкә алалар, үз фондларын яңа табылган һәм яңа сатып

алынган хәзинәләр белән тулыландыралар, реставрация һәм консервация эшләрен башкаруны һәм хәзинәләрнең саклануын тәэмин итәләр.

Музейларда, китапханәләрдә һәм архивларда саклаучы хәзинәләрне исәпкә алуның һәм аларны саклауның тәртибе законнар белән билгеләнә.

12 статья. Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә дәүләт экспертизасы

Тарих һәм мәдәният ядкярләрен саклау территорияләрендә һәм зоналарында төзелеш алып барганда, аларны хуҗалык итү ягыннан үзләштергәндә мәдәни һәм тарихи хәзинәләргә һичшиксез дәүләт экспертизасы үткәрелергә тиеш. Дәүләт экспертизасын Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы үткәрә.

13 статья. Җәмәгать оешмаларының һәм гражданнарның мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклауда һәм алардан файдалануда катнашулары

Җәмәгать оешмалары халыкны мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклауда турыдан-туры һәм актив рәвештә катнашуга җәлеп итүдә ярдәм күрсәтәләр, тарих һәм мәдәният ядкярләрен саклау буенча дәүләт органнарының эшенә ярдәм итәләр, уставларындагы бурычлары һәм максатлары нигезендә бүтән төрле вазыйфалар башкаралар.

Тарих һәм мәдәният ядкярләрен үзгәртү, бер урыннан икенче урынга күчерү яисә бөтенләй сүтү, тарихи-мәдәни әһәмияткә ия җирләрдә төзелеш алып бару яисә андагы объектларны реконструкцияләү, тыюлык директорлыкларының эшчәнлеге җирле халык фикерен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Ш бүлек. Мәдәни һәм тарихи хәзинәләргә милекчелек хокукы

14 статья. Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрнең милек рәвешләре

Татарстан Республикасының мәдәни һәм тарихи хәзинәләре

дәүләт милке, җирле үзидарә милке һәм җәмәгать берләшмәләре милке, шулай ук хосусый милек була ала.

15 статья. Мәдәни һәм тарихи хәзинәләргә дәүләт милке хокукы объектлары

Ядкярләрне саклау буенча дәүләт органнарына һәм дәүләт предприятиеләренә беркетелгән күчерелми торган мәдәни һәм тарихи хәзинәләр дәүләт милке булалар.

Табылган мәдәни һәм тарихи хәзинәләр аеруча кыйммәтле хәзинә булса, законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт милкенә бирелергә тиеш.

Яңа табылган һәм милекчесе булмаган йә милекчесе билгесез булган, йә милек хокукыннан милекчесе баш тарткан мәдәни һәм тарихи хәзинәләр законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт милкенә күчереләләр.

16 статья. Җирле үзидарәнең һәм җәмәгать берләшмәләренең мәдәни һәм тарихи хәзинәләргә милекчелек хокуклары

Законнарда билгеләнгән тәртиптә алынган күчерелә торган һәм күчерелми торган мәдәни һәм тарихи хәзинәләр җирле үзидарәнең һәм җәмәгать берләшмәләренең (оешмаларының) милекчелек хокукы объектлары булалар.

17 статья. Хуҗаларча тотылмаучы мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне сатып алу

Закон нигезендә аеруча кыйммәтле һәм дәүләт тарафыннан сакланылучы мәдәни һәм тарихи хәзинәләргә кертелгән хәзинәләрне милекче хуҗаларча тотмаса һәм аларның элеккеге әһәмиятен югалту куркынычы туса, мондый хәзинәләр хөкем карары буенча дәүләт тарафыннан сатып алу юлы белән яисә халык сәүдәсендә сатып җибәрү юлы белән милекчедән тартып алыналар.

Мәдәни хәзинәләрне сатып алганда, яклар килешүендә билгеләнгән күләмдә, ә бәхәсле очракта - суд тарафыннан милекчегә аларның хакы кайтарып бирелә.

## IV бүлек. Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклауның һәм алардан файдалануның икътисадый нигезләре

### 18 статья. Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану өлкәсен икътисадый җайга салу

Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану өлкәсен икътисадый җайга салу түбәндәгеләрне күздә тота:

- салым ташламалары һәм башка ташламалар билгеләүне;
- мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм реставрацияләү буенча гамәлләрне финанслауны;
- мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне иминләштерүне;
- дәүләт милкендәге мәдәни һәм тарихи хәзинәләрдән файдалану өчен аренда ставкаларын билгеләүне;
- мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне тоту өчен киткән чыгымнарны аларның хуҗаларына законнар нигезендә кайтарып бирүне.

### 19 статья. Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклауны һәм алардан файдалануны финанслау чыганаклары

Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклауны һәм алардан файдалануны финанслау чыганаклары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- Татарстан Республикасының республика бюджетыннан һәм җирле бюджетлардан. Мәдәни һәм тарихи мирас объектлары җәмәгать эшләре алып бару аркасында, җәмгыяви, экологик, табигый бәла-казалар һәм һәлакәтләр аркасында зыян күргән яисә җимерелгән очракларда дәүләт, бу объектларның милек рәвешләренә карамастан, аларда алып барыла торган эшләрне финанслый;
- мәдәни һәм тарихи хәзинәләр хуҗаларының, алардан файдаланучыларның һәм аларны арендага алучыларның акчаларыннан, хокукый һәм физик затларның башка кертемнәреннән;
- ядкярләрне саклау буенча дәүләт органнарының оператив идарәсендә булган тарих һәм мәдәният ядкярләреннән файдаланган өчен аренда түләвеннән;
- лицензияләр бирүдән керә торган акчалардан, мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклаучы дәүләт оешмаларының, тарих һәм мәдәният ядкярләрен манзара итүне гамәлгә ашыручы турист-экскурсия оешмаларының керемнәреннән һәм башка керемнәрдән;

- законнарда тыелмаган башка чыганаклардан керүче акчалардан.

Финанслауның барлык чыганакларыннан керүче акчалар, тарих һәм мәдәният ядкярләрен саклаучы дәүләт органнарының махсус исәпләренә билгеләнгән тәртиптә күчерелүче акчалар тарих һәм мәдәният ядкярләрен фәнни өйрәнү, саклау һәм реставрацияләү буенча дәүләт программалары һәм гамәлләре өчен, ядкярләрне саклаучы дәүләт органнарының кадрларын яңадан әзерләү өчен, ядкярләрне саклау органнарын тоту һәм аларның инфраструктурасын үстерү өчен кулланыла.

<u>20 статья.</u> Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану өлкәсендәге эшчәнлеккә салым салу

Тарих һәм мәдәният ядкярләрен саклаучы дәүләт органнары салым түләүдән законнар нигезендә азат ителәләр.

Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау, өйрәнү, реставрацияләү һәм пропагандалау белән шөгыльләнүче, нәфис сәнгатьнең, һөнәр һәм кәсепләрнең гадәти төрләрен саклауда һәм торгызуда катнашучы, шулай ук шушы максатлар өчен ирекле иганәләр кертүче хокукый һәм физик затларга законнарда билгеләнгән тәртиптә салым ташламалары бирелергә мөмкин.

<u>21 статья.</u> Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне иминләштерү

Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне иминләштерү мәҗбүри була һәм ул объектларны саклау реестрларына керткәндә башкарыла. Карамакларында һәм оператив идарәләрендә мәдәни һәм тарихи хәзинәләр булган хокукый затларга иминләштерү вазыйфалары йөкләнә.Иминләштерүдән килә торган акчалар мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау, реставрацияләү һәм алардан файдалану гамәлләренә тотыла.

<u>22 статья.</u> Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне тапкан һәм саклаган өчен гражданнарның бүләкләнү хокукы

Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне тапкан һәм саклаган өчен граждан законнар нигезендә бүләкләнергә хаклы.

## V бүлек. Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану тәртибе

**23 статья.** Тарих һәм мәдәният ядкярләрен, тарих-архитектура комплексларын саклау зоналарын һәм алардан файдалану режимнарын билгеләү

Тарих һәм мәдәният ядкярләрен, тарих-архитектура комплексларын, музей-тыюлыкларны саклауны тәэмин итү йөзеннән, законнарда билгеләнгән тәртиптә аларның территорияләренең чикләре, саклау зоналары, төзелешне җайга салу зоналары һәм сак астына алына торган табигать ландшафты зоналары, шулай ук тарихи-мәдәни максатларда кулланылучы җирләрнең кадастрлары билгеләнә.

Районнарны планлаштыру проектлары, шәһәрләрнең, поселокларның, авыл торак пунктларының генераль планнары, тарих һәм мәдәният ядкярләре булган территорияләрне детальләп планлаштыру һәм төзү проектлары саклау зоналарын, шулай ук хәзерге шартларда аларның сакланышын тәэмин итү һәм алардан файдалану гамәлләрен күздә тотарга тиешләр.

Тарих һәм мәдәниятнең күчерелми торган ядкярләренә карата түбәндәге файдалану режимнары кулланыла:

а) резервацион - хуҗалык максатларында файдалануны тыю;

б) чикләнгән рәвештә файдалану;

в) универсаль - чикләнмәгән рәвештә файдалану.

**24 статья.** Ремонт-реставрация эшләре, тарих һәм мәдәният ядкярләрен консервацияләү һәм реставрацияләү

Ремонт-реставрация эшләре, тарих һәм мәдәният ядкярләрен консервацияләү һәм реставрацияләү Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы белән килешеп гамәлгә ашырыла.

Күчерелми торган ядкярләрне реставрацияләү буенча барлык эшләр Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан бирелгән реставрация йөкләмәсе нигезендә гамәлгә ашырыла.

Ядкярләрне реставрацияләү һәм консервацияләү проектлары тиешле лицензиясе булган белгечләр җитәкчелегендә эшләнә, һәм алар Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы һәм аның

органнары белән килештерелергә тиеш.

Объектның асылына карап, археология, геология, сәнгать, архитектура тикшеренүләре һәм башка махсус тикшеренүләр уадырмый торып, мәдәни һәм тарихи әһәмияткә ия территорияләрне хуҗалык итү максатларында үзләштерү мөмкин түгел.

Тарих һәм мәдәният ядкярләрен реставрацияләү, консервацияләү һәм ремонтлау эшләре махсуслаштырылган фәнни-реставрация оешмалары, шулай ук тиешле лицензия алган ремонт-төзелеш оешмалары тарафыннан һәм реставрация белгече күзәтчелеге астында башкарыла.

25 статья. Тарихи торак урыннарын саклау

Тарих һәм мәдәният ядкярләренең зур комплекслары булган, тышкы яктан борынгы архитектура күренешен һәм планлаштыру урынының төзелмәсен саклаган һәм тарихи, мәдәни, фәнни һәм башка төр әһәмияткә ия ансамбльләре һәм комплекслары булган шәһәрләргә һәм бүтән торак пунктларына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары тарафыннан тарихи торак пунктлары статусы бирелергә мөмкин.

Тарихи торак пунктларында шәһәр күрешен тудыручы барлык төзелеш һәм сәнгать хәзинәләре сакланырга тиеш, моңа түбәндәгеләр керә: күләме һәм стиле ягыннан аерылып торучы планлаштыру, төзелеш, композиция, табигый ландшафт, археологик катлам, киң күләмле пространство төзелмәсе, фрагментлы һәм җимерелгән шәһәр калдыклары, биналарның һәм корылмаларның рәвеше һәм төре.

26 статья. Күчерелми торган ядкярләре булган шәһәрләрнең һәм башка торак пунктларының төзелеш документларын тарих һәм мәдәният ядкярләрен саклау буенча дәүләт органнары белән килештерү

Күчерелми торган тарих һәм мәдәният ядкярләре булган шәһәрләрнең һәм башка торак пунктларының төзелеш документлары Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы белән килештерелергә тиеш.

27 статья. Тарихи-мәдәни тыюлыкларны һәм тыюлык территорияләрен саклау

Аеруча зур тарихи, фәнни, сәнгати һәм башка мәдәни әһәмияткә ия булган тарих һәм мәдәният ядкярләренең ансамбльләренә һәм комплексларына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан тарихи-мәдәни тыюлыклар, тыюлык территорияләре статусы бирелергә мөмкин һәм алар махсус саклананалар.

28 статья. Яңа табылган мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау

Тарихи, фәнни, сәнгати һәм башка мәдәни кыйммәткә ия яңа табылган мәдәни һәм тарихи мирас объектлары, аларны саклау реестрына кертү-кертмәү турындагы мәсьәлә хәл ителгәнчегә кадәр, законнардагы таләпләр нигезендә сакланырга тиешләр.

29 статья. Күчерелми торган тарих һәм мәдәният ядкярләрен сүтүне, башка урынга күчерүне һәм үзгәртүне тыю

Күчерелми торган тарих һәм мәдәният ядкярләрен сүтү, башка урынга күчерү һәм фасадларын, интерьерларын үзгәртү тыела. Аерым очракларда гына, җирле халыкның фикерен искә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты рөхсәте белән күчерелми торган тарих һәм мәдәният ядкярләрен сүтәргә, башка урынга күчерергә, фасадларын һәм интерьерларын үзгәртергә мөмкин.

Шундый рөхсәт алган хокукый һәм физик затлар тарих һәм мәдәният ядкярләренең фасадларын һәм интерьерларын сүткәндә, икенче урынга күчергәндә яисә үзгәрткәндә тарих һәм мәдәният ядкярләрен фәнни өйрәнү буенча эшләр башкарырга тиеш.

30 статья. Төзелеш эшләрен һәм бүтән эшләрне башкарганда мәдәни һәм тарихи хәзинәләрнең сакланышын тәэмин итү

Тарих һәм мәдәният ядкярләре өчен куркыныч тудырырлык тә-

җелеш, мелиорация, юл эшләре һәм башка эшләр Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы рөхсәте буенча һәм тарих һәм мәдәният ядкярләренең сакланышын тәэмин итәрлек гамәлләрне үтәгәч кенә башкарыла.

Ядкярләрне саклау зоналарында, тыюлык территорияләрендә һәм тыюлык урыннарында, тарихи шәһәрләрдә һәм бүтән торак пунктларында башкарырга планлаштырылучы төзелеш эшләренең, юл, мелиорация эшләренең һәм башка эшләрнең проект йөкләмәләре, техник-икътисадый нигезләүләре һәм проектлары Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы белән килештерелергә һәм бу хәзинәләрнең сакланышын тәэмин итәрлек гамәлләр үтәлүне күздә тотарга тиеш.

Әлеге гамәлләргә түбәндәгеләр керә: ядкярләрне табу - барлау, тикшерү, археологик казынулар үздыру, табылдык әйберләрне музейларга тапшыру, реставрацияләү, тарих һәм мәдәният ядкярләрен саклау буенча дәүләт органнары күрсәтмәсе нигезендә башкарылучы бүтән эшләрне үтәү.

Ядкярләрне саклау зоналарында төзелеш алып бару өчен яисә башка төр хуҗалык эшчәнлеге өчен җир бирү турындагы карар Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы белән килештерелергә тиеш.

Хуҗалык эшләре барышында тарихи, фәнни әһәмияткә, сәнгати һәм башка төр мәдәни әһәмияткә ия булырлык объектларга тап булганда, хокукый һәм физик затлар бу турыда Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына хәбәр итәргә һәм, махсус рөхсәт алганчы, башкарыла торган эшләрне туктатып торырга тиешләр.

Табу-барлау, тикшерү, килештерү гамәлләре һәм башка төр саклау гамәлләре төзелеш, мелиорация, юл эшләрен һәм башка эшләрне башкаручы хокукый һәм физик затлар хисабыннан финанслана.

<u>31 статья.</u> Археология ядкярләрен эзләү һәм казып алу

Археология ядкярләрен эзләүне һәм казып алуны бары тик Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе тарафыннан бирелә торган һәм билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында теркәлүче рөхсәтләр (ачык листлар) булганда гына башкарырга мөмкин.

32 статья. Тарих һәм мәдәният ядкярләрен файдалануга тапшыру

Дәүләт милкендәге тарих һәм мәдәният ядкярләре Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тәкъдиме буенча билгеләнгән тәртиптә хокукый һәм физик затларга файдалану өчен тапшырылырга мөмкин.

Торак биналары рәвешендәге һәм башта билгеләнгән максатларда файдаланылучы ядкярләр Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан саклау йөкләмәсе төзү юлы белән торактан файдалану предприятиеләренә яисә гражданнарга тапшырыла алалар.

Гыйбадәт кылу өчен билгеләнгән ядкәрләр дини оешмаларга файдалану өчен түләүсез тапшырылырга мөмкин. Дини җәмгыятьләр тарих һәм мәдәният ядкярләренннән, аларның аерым биналарыннан, шулай ук аларга бәйле территорияләрдән һәм корылмалардан хуҗалык максатларында файдаланганда саклау-арендалау шартнамәләре төзелә.

Дәүләт һәм җәмәгать китапханәләренең, музейларының, архивларының, фәнни-тикшеренү институтларының һәм учреждениеләренең фондларындагы күчерелә торган хәзинәләр шушы учреждениеләр идарәсендә булалар һәм законнар нигезендә алардан файдаланалар.

33 статья. Тарих һәм мәдәният ядкярләреннән файдалану тәртибе һәм шартлары

Тарих һәм мәдәният ядкярләреннән файдалану тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә, ул хокукый һәм физик затларның милкендә яисә файдалануында булган һәр ядкяр өчен тиешле саклау документы - саклау-арендалау документы, саклау шартнамәсе, саклау йөкләмәсе нигезендә аерым билгеләнә.

Ядкярләрдән файдалануның, аларны яңгыннан саклауның саклау документларында билгеләнгән тәртибен үтәү өчен җаваплылык бу ядкярләр аларның милкендә яисә файдалануында булган предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның җитәкчеләренә һәм гражданнарга йөкләтелә.

Тарих һәм мәдәният ядкярләреннән файдаланган өчен аренда түләве ставкалары Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

34 статья. Мәдәни һәм тарихи хәзиналәр милекчеләренең, алардан файдаланучыларның хокуклары

Мәдәни һәм тарихи хәзиналәрнең милекчеләре һәм алардан файдаланучылар түбәндәгеләргә хаклы:

- тарих һәм мәдәният ядкярләрен ремонтлау-консервацияләү өчен, һәлакәтләрне булдырмау буенча эшләр башкару өчен, саклау йөкләмәләренең яисә саклау-арендалау шартнамәләренең шартларын, әлеге эшләрне башкару кагыйдәләрен үтәгән тәкъдирдә, дәүләт органнарыннан матди ярдәм алырга;

- мәдәни һәм тарихи хәзиналәрне түләүсез исәпкә куйдырырга һәм теркәтергә, аларны исәпкә алу документларын тутырырга, шулай ук законнар нигезендә башка хокукларга ия.

35 статья. Мәдәни һәм тарихи хәзиналәр милекчеләренең, алардан файдаланучыларның бурычлары

Мәдәни һәм тарихи хәзиналәрнең милекчеләре, алардан файдаланучылар түбәндәгеләргә бурычлы:

- мәдәни һәм тарихи хәзиналәрне саклауның, реставрацияләүнең һәм алардан файдалануның законнарда билгеләнгән тәртибен һәм кагыйдәләрен үтәргә;

- билгеләнгән тәртиптә саклау йөкләмәләре, саклау һәм саклау-арендалау шартнамәләре төзергә;

- ядкярләрне тиешле тәртиптә тотарга, аларны ремонтларга, реставрацияләргә, аларны саклау буенча башка гамәлләр эшләргә;

- мәдәни һәм тарихи хәзиналәргә милекчелек рәвешләрен, аларның урынын, аларны тоту шартларын үзгәртүне, шулай ук аларны реставрацияләү буенча алып барыла торган эшләрне Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы белән килештерергә;

- Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының күрсәтмәләрен үтәргә;

- тарих һәм мәдәният ядкярләрен карап чыгу мөмкинлеген,

фәнни, тәрбия-агарту максатларында һәм башка максатларда археология, консервация һәм реставрация эшләре алып бару мөмкинлеген тәэмин итәргә;

- үзләре карамагындагы яисә файдаланылучы мәдәни һәм тарихи хәзинәләрнең документларын сакларга һәм аларны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына һәм аның урыннардагы органнарына тапшырырга.

VI бүлек. Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә чит дәүләтләр белән хезмәттәшлек

36 статья. Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану турындагы Татарстан Республикасы законнарының халыкара конвенцияләр, шартнамәләр һәм килешүләр белән үзара бәйләнеше

Татарстан Республикасы чит дәүләтләр һәм халыкара оешмалар белән мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану буенча шартнамәләр һәм килешүләр төзи.

Халыкара хокук нормалары һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнар нигезендә Татарстан Республикасы мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау буенча халыкара программаларда, кампанияләрдә һәм акцияләрдә катнаша.

Әгәр Татарстан Республикасының халыкара шартнамәсендә мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау турындагы законнардагыдан бүтән кагыйдәләр билгеләнгән булса, халыкара шартнамә кагыйдәләре кулланыла.

37 статья. Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне читкә чыгару һәм читтән кертү

Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне читкә чыгару һәм читтән кертү Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнарда билгеләнгән тәртиптә тормышка ашырыла.

Татарстан Республикасы территориясеннән законсыз читкә чыгарылган мәдәни һәм тарихи хәзинәләр кайтарып бирелергә тиеш.

38 статья. Татарстан Республикасының үзеннән читтә урнашкан мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне кайгыртуы

Татарстан Республикасы үзеннән читтә урнашкан мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне дәүләтара һәм хөкүмәтара шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә кайгыртып тора.

VII бүлек. Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану турында Татарстан Республикасы законнарын бозган өчен җаваплылык

39 статья. Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану турында Татарстан Республикасы законнарын бозган өчен җаваплылык

Әлеге Законны бозган өчен законнар нигезендә хокукый җаваплылык билгеләнә.

40 статья. Тарих һәм мәдәният ядкярләрен торгызу һәм тарихи һәм мәдәни хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану өлкәсендәге законнарны бозу рәвешендә китерелгән зыянны кайтару

Тарих һәм мәдәният ядкярләренә, ядкярләрне саклау зоналарына зыян китергән хокукый һәм физик затлар ядкярләрне, ядкярләрне саклау зоналарын янадан торгызырга, ә моны башкара алмаганда, зыянны законнар нигезендә кайтарырга тиешләр.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1996 елның 2 октябре
N 755

macsburo/zakon/4/tarih.txt